***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ

# ҖАВАПЛАРЫ

(2025-2026 нчы уку елы)

**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 54**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Татар телендә генә булган сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [и]
   **ә) [ө]**
   б) [у]
   в) [а]
2. [w] авазы кулланылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) завод
   ә) Саттаров
   б) велосипед
   **в) тау**
3. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) яза
   ә) язам
   **б) язабыз**
   в) яздым
4. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) урман
   **ә) китап**
   б) диңгез
   в) каен
5. ***Каты*** сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) каты күз**
   ә) каты кабак
   б) каты аңкау
   в) каты таракан
6. Сүз ясагыч кушымчасы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) күзләр
   **ә) күзлек**
   б) күз-колак
   в) күзләрне
7. Иялек килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) агачның**
   ә) агачка
   б) агачтан
   в) агачта

8. Зат алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) укучы
ә) кем
б) шул
**в) син**

9. Боерык фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) утыр**
ә) утырам
б) утырдым
в) утырган

10. Җөмләнең хәбәрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Иртәгә мәктәптә спорт ярышлары узачак.*
а) спорт
ә) мәктәптә
б) ярышлары
**в) узачак**

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Ике кешенең аралашуы диалог дип атала. Авазларны әйтү өчен, сөйләм органнары кирәк. [э] авазы сүз башында э хәрефе белән бирелә. Мәгънәләре охшаш булган сүзләр синонимнар дип атала. Нечкә әйтелешле сүзгә нечкә кушымча ялгана. Фигыль барлыкта һәм юклыкта килә.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Кушма сүзләрнең беренче компонентларын уйлап языгыз. **(4 балл)**

| | |
|---|---|
| гөлҗимеш | төнбоек |
| тимераяк | көнбагыш |

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**
Белым ковром лёг снег на поля.Снежные шубы надели сосны и ели. Толстый лёд сковал реки.
2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

КЫШ БАБАЙ

Кыш бабай килгән,
Ап-ак тун кигән.
Көтә: кем генә
Чыгар дип өйдән.

Чыксаң өшетә,
Битне чеметә.
Менә шул аның
Бөтен эше дә.

(*Бари Рәхмәт*)

2.1. Юлдан юлга күчереп булмый торган ике иҗекле сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл) аның, эше** (артык сүз язылса, балл киметелә!)
2.2. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(2 балл)**
кигән – **салган** ап-ак – **кап-кара**

2.3. Зат алмашлыгын күчереп языгыз, килешен билгеләгез. **(2 балл)**
**(анын – иялек килешендә)**

2.4. Билгесез үткән заман хикәя фигыльләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**
**килгән, кигән** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

3. **«Кар бабай ясыйбыз»** темасына 6-8 җөмләдән торган инша языгыз. **(10 балл)**